Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Сухрау торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2021 елның 23 октябрь № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 23 октябрьдә уздырылган « Түбән Кама муниципаль районының Сухрау авыл җирлеге Сухрау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарны, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманын 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидар һәм 80 яшьтән узганнар түли, ярминкә өчен павильон төзү өчен алынган акчаларның юнәлеше

ӘЙЕ ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 440 граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашучы гражданнар саны 325 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 325 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Сухрау авыл җирлеге составына керүче Сухрау торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, халык җыены нәтиҗәләрен чын дип таныргa.

2.« Түбән Кама муниципаль районының Сухрау авыл җирлеге Сухрау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1нче төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылары, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннарны, көндезге уку формасы буенча белеем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә 2022 елда үзара салым кертергә. Әлеге сумманын 50% күләмендә 2 нче төркем инвалидар һәм 80 яшьтән узганнар түли, ярминкә өчен павильон төзү өчен алынган акчаларның юнәлеше

ӘЙЕ ЮК».

Мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Сухрау авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сухрау авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Галимов